МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ

БОЕРЫК

06.09.2019 Казан ш. № 2728-р

**Татарстан Республикасының Кайбыч, Кама Тамагы муниципаль районнары территориясендәге газ бүлү челтәрләре объектларының саклык зонасы чикләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Республика газ бүлү челтәрләре» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «ГазКомплектСервис» ҖЧҖ башкарган документациягә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районы территориясендәге бүлгеч газүткәргеч объектларының («Югары басымлы газүткәргечнең закольцовкасы АГРС Олы Кайбыч т.п. – АГРС Тат. Наратлы

т.п.») 16 814 кв.м гомуми мәйданлы территория рәвешендәге саклык зонасын 2019 елның 23 июленнән 2019 елның 02 августына кадәр «ГазКомплектСервис» ҖЧҖ башкарган һәм 2019 елның 02 августында «Республика газ бүлгеч челтәрләре» ҖЧҖ тарафыннан расланган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районы территориясендәге бүлгеч газүткәргеч объектларының («Кама Тамагы ш.т.бның Профсоюз ур. буенча 1.2 поз. торак йортларга урта басымлы газүткәргечнең тармаклануы») 1 207 кв.м гомуми мәйданлы территория рәвешендәге саклык зонасын 2019 елның 23 июленнән 2019 елның 02 августына кадәр «ГазКомплектСервис» ҖЧҖ башкарган һәм 2019 елның 02 августында «Республика газ бүлгеч челтәрләре» ҖЧҖ тарафыннан расланган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә расларга.

3. Бүлгеч газүткәргечне эксплуатацияләү срогында әлеге карарның 1 - 2 пунктларында күрсәтелгән газ бүлгеч челтәре объектларының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр в.б.** **А.И.Галиев**